ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2022 г. Казань № 188-32/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Химград» технополисы территориясендә су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларының технологик зонасында «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын су транспортлауга һәм агып җыела торган суларны транспортлауга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Химград» технополисы территориясендә су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларының технологик зонасында «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын су транспортлауга һәм агып җыела торган суларны транспортлауга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №649-173/кс-2021, 17.08.2022 №129-27/кс-2022 карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга Идел су алу корылмасының икенче күтәрелешендәге су үткәрү төене зонасында «Химград» технополисы территориясендә су үткәрү челтәрләре буенча салкын суны транспортлауга һәм Төньяк-сәнәгать коллекторы зонасында «Химград» технополисы территориясендә канализация челтәрләре буенча агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүлеп, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ) өчен Идел су алу корылмасының икенче күтәрелешендәге су үткәрү төене зонасында «Химград» технополисы территориясендә су үткәрү челтәрләре буенча салкын суны транспортлауга һәм Төньяк-сәнәгать коллекторы зонасында «Химград» технополисы территориясендә канализация челтәрләре буенча агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләргә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен Идел су алу корылмасының икенче күтәрелешендәге су үткәрү төене зонасында «Химград» технополисы территориясендә су үткәрү челтәрләре буенча салкын суны транспортлауга һәм Төньяк-сәнәгать коллекторы зонасында «Химград» технополисы территориясендә канализация челтәрләре буенча агынты суларны транспортлауга 2021-2025 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.»;

1 нче кушымтада:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен 2021-2025 елларга Идел су алу корылмасының икенче күтәрелешендәге су үткәрү төене зонасында «Химград» технополисы территориясендә су үткәрү челтәрләре буенча салкын суны транспортлауга һәм Төньяк-сәнәгать коллекторы зонасында «Химград» технополисы территориясендә канализация челтәрләре буенча агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар»;

1 нче пунктның «Муниципаль берәмлекнең атамасы, салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың исеме» графасында «Химград» технополисының су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларының технологик зонасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче кушымтада:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен 2021-2025 елларга Идел су алу корылмасының икенче күтәрелешендәге су үткәрү төене зонасында «Химград» технополисы территориясендә су үткәрү челтәрләре буенча салкын суны транспортлауга һәм Төньяк-сәнәгать коллекторы зонасында «Химград» технополисы территориясендә канализация челтәрләре буенча агынты суларны транспортлауга тарифларны җайга салуның календарь буенча бүленгән озак сроклы параметрлары»;

1 нче пунктның «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың исеме» графасында «Химград» технополисының су

белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларының технологик зонасында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев